МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 151 / о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 30 » 09 2021

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыклары гамәлдән чыккан дип танырга:

«Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентын раслау хакында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 08 декабрендәге 204/о номерлы;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 24 маендагы 90/о номерлы.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ *
Отдел контроля исполнения документов